| | | |
|---|---|---|
| **РАСПОРЯЖЕНИЕ**<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>**БОЕРЫГЫ** |

27.08.2019 № 300

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау мәсьәләләре буенча ведомствоара эш төркеме турында» боерыгына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау мәсьәләләре буенча ведомствоара эш төркеме турында» 2016 елның 7 мартындагы 170 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Президентының 2018 елның 11 маендагы 184 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау мәсьәләләре буенча ведомствоара эш төркеме турында нигезләмәнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау мәсьәләләре буенча ведомствоара эш төркеме (алга таба – Эш төркеме) министрлыклар, ведомстволар, башка дәүләт органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары һәм оешмаларның түбәндәге чараларны гамәлгә ашыру эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итү өчен оештырылган ведомствоара орган булып тора:

Россия Федерациясе Президенты тарафыннан 2018 елның 28 декабрендә расланган Пр-2665 номерлы 2019–2023 елларга Россия Федерациясендә террорчылык идеологиясенә каршы көрәшү комплекслы планын;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 16 октябрендәге 764 номерлы карары белән расланган «2014–2021 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәшү» дәүләт программасының «2014–2021 елларга Татарстан Республикасында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау» ярдәмче программасын.»;

Татарстан Республикасында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау мәсьәләләре буенча ведомствоара эш төркеме составын кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Татарстан Республикасы
Президентының
2019 елның «_27_» августындагы
_300_ номерлы боерыгына
кушымта

**Татарстан Республикасында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау мәсьәләләре буенча ведомствоара эш төркеме составы**

| | |
|---|---|
| Гыйльманов<br>Рафаил Вәли улы | Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы Секретаре, ведомствоара эш төркеме җитәкчесе |
| Нигъмәтуллин<br>Рөстәм Камил улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары, ведомствоара эш төркеме җитәкчесе урынбасары |
| Галиев<br>Илдар Шамил улы | Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге мөдире, ведомствоара эш төркеме секретаре |
| Барышев<br>Александр Георгиевич | Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы башкарма секретаре (килешү буенча) |
| Береснев<br>Павел Васильевич | Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Вәлиуллов<br>Рөстәм Фәйзрахман улы | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрының беренче урынбасары |
| Захматова<br>Анна Андреевна | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры урынбасары |

| | |
|---|---|
| Зиннуров<br>Фоат Кәнәфи улы | Татарстан Республикасы югары уку йортлары студентлары арасында экстремистлыкны профилактикалау, милләтара низагларны булдырмау буенча вузара комитет рәисе, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик институты башлыгы (килешү буенча) |
| Минголов<br>Алмаз Минвазыйх улы | Татарстан Республикасы спорт министры урынбасары |
| Миргалимов<br>Илдар Флүс улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе урынбасары |
| Мөхәрләмов<br>Руслан Роберт улы | Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе урынбасары |
| Поминов<br>Андрей Иванович | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары |
| Сафина<br>Зөлфия Нурмөхәммәт кызы | «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Аппараты» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Соколов<br>Алексей Владимирович | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры урынбасары – полиция башлыгы (килешү буенча) |
| Фәйзрахманов<br>Марат Җәүдәт улы | Татарстан Республикасы финанс министрының беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты директоры |
| Фатыйхов<br>Илдар Разин улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры урынбасары |
| Хәкимҗанов<br>Ленар Сәетҗан улы | Татарстан Республикасы мәдәният министры урынбасары |
| Хиялиев<br>Эдуард Данил улы | Җәзаларны үтәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгының беренче урынбасары (килешү буенча) |

---